**РЕШЕНИЕ**
**Азнакаевского районного Совета Республики Татарстан**

Азнакай шәһәре №288-39_____ «22» октябрь 2019 ел

Азнакай муниципаль районы Советының 20.04.2011 ел №48-8 «Азнакай муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы «муниципаль казна учреждениесе турындагы Нигезләмә хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында (10.04.2014 №297-42, 22.05.2014 №306-44, 15.02.2019 №235-34 карарлар редакциясендә)

«Дәүләт (муниципаль) бурыч алулары, дәүләт (муниципаль) бурычлары һәм Россия Федерациясенең дәүләт (муниципаль) финанс активлары белән идарә итү өлкәсендә мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салуны камилләштерү һәм "дәүләт һәм муниципаль кыйммәтле кәгазьләр эмиссиясе һәм мөрәҗәгать итү үзенчәлекләре турында" Федераль законның үз көчен югалтуын тану максатларында Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 02.08.2009 ел №278-ФЗ Федераль закон нигезендә һәм «Азнакай муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесе турындагы нигезләмәләрне төгәлләштерү максатларында

Татарстан Республикасы Азнакай район Советы **карар чыгарды:**

1. Азнакай муниципаль районы Советының 20.04.2011 ел №48-8 «Азнакай муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы «муниципаль казна учреждениесе турындагы Нигезләмә хакында» карарына (10.04.2014 №297-42, 22.05.2014 №306-44, 15.02.2019 №235-34 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарның исемен «Татарстан Республикасы» сүзләре белән тулыландырырга;

1.2. 1.1. пунктта «районның» сүзеннән соң «Татарстан Республикасы» сүзләрен өстәргә;

2. Азнакай муниципаль районы Советының 20.04.2011 ел №48-8 (10.04.2014 №297-42, 22.05.2014 №306-44, 15.02.2019 №235-34 карарлар редакциясендә) карары белән расланган «Азнакай муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

2.1. наименование Положения дополнить словами «Республики Татарстан»;

2.2. 1 бүлекнең 1.1., 1.2. пунктларында «районның» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасы» сүзләрне өстәргә;

2.3. 3 бүлекнең 3.2.2 пункты үз көчен югалткан дип санарга;

2.4. 3 бүлекнең 3.2.3 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«3.2.3. район Башкарма комитеты актлары нигезендә банк гарантиясенең, поручительствоның ышанычлылыгын бәяләүне гамәлгә ашыру;»;

2.5. 3 бүлекнең 3.2.4 пункты үз көчен югалткан дип санарга;

2.6. 3 бүлекнең 3.2.5, 3.2.6 пунктларын яңа редакциядә бәян итәргә:

«3.2.5. принципалның финанс хәлен анализлау, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 115.2 статьясындагы 1.1 пунктының өченче абзацы нигезендә бирелә торган тәэминатның җитәрлеклеген, ышанычлылыгын һәм ликвидлылыгын тикшерү, муниципаль гарантия биргәндә, шулай ук принципалның финанс хәле мониторингын, муниципаль гарантия биргәннән соң бирелгән тәэминатның җитәрлек булуын, ышанычлылыгын һәм ликвидлылыгын тикшерү;

3.2.6. бирелгән гарантияләрне исәпкә алуны алып бару, алар буенча муниципаль бурычны арттыру, принципаллар йә өченче затлар тарафыннан гарантияләр белән тәэмин ителгән принципаллар йөкләмәләренең тулы күләмдә яисә нинди дә булса өлешендә муниципаль бурычны киметү, принципалларның гарантияләр белән тәэмин ителгән йөкләмәләренең тулы күләмдә яисә нинди дә булса өлешендә туктатылу, бирелгән гарантияләр буенча Гарант тарафыннан түләүләр башкарылу, шулай ук муниципаль гарантияләр белән билгеләнгән башка очракларда».

3. Әлеге карарның 2.3. – 2.6. пунктлары 2020 елның 01 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында http://aznakayevo.tatar.ru адресы буенча урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Азнакай район Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Рәис М.З.Шәйдуллин